**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**21 ноябрь, 2022 ел** **№ 225**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 23 сентябрендәге 4 номерлы карарына (23.09.2020 №4, 12.11.2021 №122, 31.03.2022 №156, 12.10.2022 №212 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «11498» саннарын «12688» саннарына алмаштырырга.

2. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220

номерлы карарына (23.09.2020 №4, 12.11.2021 №122, 31.03.2022 №156, 12.10.2022 №212 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 33592 |
| Муниципаль район башлыгының урынбасары | 30233 |
| Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе | 30233 |

2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре» 2 нче кушымтасындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| N т/б | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 32989 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 29944 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 29690 |
| 4. | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 29563 |
| 5. | Заместитель руководителя иного органа местного самоуправления | 27152 |
| 6. | Башкарма комитет аппараты (эшләр идарәчесе) җитәкчесе | 27786 |
| 7. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 24107 |
| 8. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 23092 |
| 9. | Башкарма комитет аппаратының идарә башлыгы | 22838 |
| 10. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 20174 |

| | | |
|---|---|---|
| 11. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе | 20174 |
| 12. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек җитәкчесе | 20174 |
| 13. | Сектор җитәкчесе | 18651 |
| 14. | Баш белгеч | 17890 |
| 15. | Әйдәп баручы белгеч | 16621 |

әлеге карарга «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләү күләме һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе» 6 нчы кушымтасындагы «1 процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы мактаулы исеме өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәне гамәлгә ашыру һәм аның күләме» 13 нче кушымтасында 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Өстәмә түләүләр ай саен башкарыла һәм ай саен хезмәт өчен түләү фонды буенча акчаларны экономияләү исәбенә яисә муниципаль берәмлек бюджетында, җирле үзидарә органында өстәмә керем булганда (хезмәт өчен түләү фондыннан тыш) акчалар исәбенә түләнә»;

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын төзү тәртибе» 15 нче кушымтасындагы 6 пунктында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов